РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**СОВЕТ БОЛЬШЕЧЕКМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ЧАКМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ЧАКМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ V ЧАКЫРЫЛЫШ VIII УТЫРЫШЫ

## К А Р А Р № 14

Олы Чакмак авылы

«09» апрель 2026 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Олы Чакмак авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Олы Чакмак авыл җирлеге советының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

1.1 “Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти хезмәт вазыйфалары турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында” гы 2014 елның 18 нче декабрендәге 4 нче номерлы карарын;

1.2 «Мөслим муниципаль районының Олы Чакмак авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче, контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгүлүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару тәртибен раслау” турындагы 2017 нче елның 08 нче сентябрендәге 17 нче номерлы карарын;

1.3 “Мөслим муниципаль районының Олы Чакмак авыл җирлегендә

муниципаль вазыйфалар,контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгүлүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару тәртибен раслау" турындагы 2017 нче елның 11 нче сентябрендәге 17 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турындагы 2022 нче елның 28 нче сентябрендәге 45 нче номерлы карарын;

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Олы Чакмак авыл җирлеге башлыгы** **И.М.Габидуллин**